ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӨРБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«03» июнь 2020 ел.

**КАРАР**
№ 9

**Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентларны раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, 2010 елның 2 ноябрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 нче карарына, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр” 2019 ел 19 апрель 167 карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Капиталь төзелеш объектын шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан планлаштырылган капиталь төзелеш объектын сүтү турында хәбәрнамәләр һәм документлар урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 кушымта).

1.2. Капиталь төзелеш объектын шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү һәм төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының бу хакта мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлану турында хәбәрнамәне урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 кушымта).

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән административ регламентлар нигезләмәләре электрон формада “дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә расланган электрон формада дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүгә күчү план-графигы белән билгеләнгән срокларда кулланыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге башкарма комитетының №39 “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2019 нчы елның 16 декабрендә чыккан карарын үз көчен югалткан дип санау хакында”.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Балтач муниципаль районы
Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Галимуллин